РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«03» июль 2023 ел Олы Кайбыч ав. №201

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасы рәисенең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгының, Башлык урынбасарының, Контроль-хисап палатасының, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы турында» 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«мактаулы исемнәр өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү билгеләү тәртибе каралганча (6 нчы кушымта);»;

түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларны һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт узучы (узган) затларны бер мәртәбә акчалата бүләкләү турында нигезләмә (7 нче кушымта).

1.2. түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына 6нчы кушымта

## ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДКА МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР ӨЧЕН АЙЛЫК ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮ БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ

1. Өстәмә түләү билгеләү өчен муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган Татарстан Республикасы мактаулы исеме булу нигез була.

2. Татарстан Республикасы мактаулы исеме булган муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә түләү вазыйфаи окладның 5 проценты күләмендә билгеләнә.

Татарстан Республикасының мактаулы исеме өчен аны берничә нигез буенча алырга хокукы булган муниципаль хезмәткәргә өстәмә түләү муниципаль хезмәткәр сайлавы нигезендә берсе буенча билгеләнә.

3. Өстәмә түләү ай саен һәм акчалар белән бергә җирле үзидарә органының (муниципаль орган) хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

4. Муниципаль хезмәткәрләргә әлеге түләүне билгеләү турындагы карар җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе тарафыннан кабул ителә.».

1.3. түбәндәге эчтәлекле 7 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 242 номерлы карарына 7 нче кушымта

## Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларны һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт узучы (узган) затларны бер мәртәбә акчалата бүләкләү турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче муниципаль хезмәткәргә (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр), шулай ук Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәттән азат ителгән Россия Федерациясе гражданнарына бүләкләү яисә акчалата бүләкләү бирелгәннән соң бер мәртәбә акчалата бүләкләү түбәндәге күләмнәрдә түләнә:

а) Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы тарафыннан бүләкләнгәндә - муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүнең 0,2 оклады күләмендә;

б) Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан бүләкләнгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүнең 0,5 оклады күләмендә;

в) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүнең 1,5 окладны күләмендә;

г) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан бүләкләнгәндә - муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүнең бер окладны күләмендә;

д) Россия Федерациясе дәүләт бүләге белән бүләкләгәндә – муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә айлык акчалата түләүнең ике окладны күләмендә.

2. Бер тапкыр акчалата бүләкләү Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының хокукый акты яисә бүләкләү турында муниципаль хокукый акт басылган датасыннан муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның һәм муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата түләү күләменнән, ә гражданнарга карата - аларның эштән китүе турында акт чыгару датасыннан чыгып түләнә.

3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка, муниципаль хезмәткәргә яисә гражданга бер мәртәбә акчалата бүләкләү Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең күрсәтелгән зат муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән яисә били торган муниципаль органы тарафыннан күрсәтелгән затка тиешле муниципаль орган хезмәте өчен түләү фонды акчалары исәбеннән бүләкләү яисә акчалата бүләкләү турында хокукый акт басылып чыккан көннән алып 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль
районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин